**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№425**
**31.01.2019**

Яр Чаллы шәһәренең «Төзүче» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезнамә, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Төзүче» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 31 гыйнварындагы
425 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«Төзүче» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле
өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең<br>һәм (яки) түләүле муниципаль хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| 1. | Футбол кыры бирү (ясалма өслек) | 60 минут | 4000,00 |
| 2. | Футбол кыры бирү (табигый өслек) | 60 минут | 1500,00 |
| 3. | Мини футбол кыры бирү | 60 минут | 1000,00 |
| 4. | Йөгерү юллары бирү | 60 минут | 1000,00 |
| 5. | Спорт-сәламәтләндерү чаралары оештыру | 60 минут | 1000,00 |
| 6. | Волейбол һәм баскетбол өчен мәйданчык бирү | 60 минут | 600,00 |
| 7. | Матч оештыру | 1 матч | 45 000,00 |
| 8. | Велосипедларны прокатка бирү | 60 минут | 170,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова